КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 май г.Казань № 367

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекТән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү эшчәнлеген оештыру турында» 2009 ел, 29 июль, 631 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекТән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү эшчәнлеген оештыру турында» 2009 ел, 29 июль, 631 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пробация кулланыла торган затларның социаль тәртибен коррекцияләү, аларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү мәсьәләләрен хәл итү, аларның яңа җинаятьләр кылуын кисәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составын;

«Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен

гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турындагы бертип нигезләмәне.»;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта:

икенче абзацта «иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү» сүзләрен «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына үткәрелә торган эшне исәпкә алуны тәэмин итү максатларында «Пробация кулланыла торган затларның ярдәм реестры» дәүләт мәгълүмат системасының төбәк сегментын алып баруны тәэмин итү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркемгә карауга кертергә.»;

әлеге карар белән расланган Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә булышлык күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны яңадан социальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турындагы бертип нигезләмәне (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 29 июль, 631 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 27 май, 367 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турында
нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – Эшче төркем) Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль законны гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре, Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге), Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмалары хезмәттәшлеген тәэмин итә торган даими эшләүче орган булып тора.

1.2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Россия Федерациясендә пробация турында» 2023 елның 6 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының хөкем ителгәннәр һәм җинаять җәзасын үтәгән затлар хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган нормалар бирелгән башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр «Россия Федерациясендә пробация турында» 2023 елның 6 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

1.3. Эшче төркемнең бурычлары – социаль элемтәләрне торгызу, һөнәри күнекмәләргә ихтыяҗ булу һәм эшкә урнашу, хокукларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны торгызу, торак белән тәэмин итү, белем алу, социаль хезмәт күрсәтү, пенсия белән тәэмин итү хокукларын гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе законнары нигезендә медицина, психологик һәм юридик ярдәм күрсәтелү

мәсьәләләрендә пробация кулланыла торган затларга ярдәм күрсәтү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру буенча пробация субъектлары эшчәнлеген координацияләү.

1.4. Эшче төркемнең эшчәнлеге яңадан социальләштерүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә булышлык күрсәтелү карала торган затларның ихтыярый теләк белдерүе һәм иреге принципларына нигезләнә.

## II. Эшче төркем вәкаләтләре

2.1. Эшче төркем үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

пробация кулланыла торган затларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү чараларын планлаштырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмалар хезмәттәшлеген тәэмин итү;

халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү, хөкемгә тартылган затларны, мәҗбүри эшләр һәм иректән мәхрүм итү рәвешендә җәзалар үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү өлкәсендә норматив хокукый актлар эшләү буенча, хөкемгә тартылган затларны, мәҗбүри эшләр һәм иректән мәхрүм итү рәвешендә җәзалар үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны яңадан социальләштерүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль тернәкләндерүгә юнәлдерелгән чаралар карала торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү һәм кабул итү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

хөкемгә тартылган затларны, мәҗбүри эшләр һәм иректән мәхрүм итү рәвешендә җәзалар үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар, пробация кулланыла торган затларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә мәҗбүри эшләр яки иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үткән затларга һәм (яки) тормышта авыр хәлдә калган, җинаять-хокук характерында башка чаралар билгеләнгән затларга социаль хезмәтләр күрсәтү, хөкемгә тартылган затларны, мәҗбүри эшләр һәм иректән мәхрүм итү рәвешендә җәзалар үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны эшкә урнаштыручы эш бирүчеләрне икътисадый стимуллау чараларын эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр һәм тәкъдимнамәләр әзерләү;

пробация кулланыла торган затларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәлелегенә һәм эффективлыгына анализ ясау.

## III. Эшче төркем формалаштыру тәртибе

3.1. Эшче төркем Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Эшче төркем җитәкчесе, аның урынбасарлары һәм Эшче төркем әгъзалары составында төзелә. Эшче төркем җитәкчесе – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары.

3.2. Эшче төркем составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкилләре керә. Моннан тыш, Эшче төркем составына килешү буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, дини оешмалар, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар, социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, фәнни, медицина оешмалары, индивидуаль эшкуарлар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре кертелергә мөмкин.

3.3. Эшче төркем эшчәнлегендә катнашу иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

3.4. Эшче төркем утырышларына дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

## IV. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

4.1. Эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

4.2. Эшче төркем утырышлары Эшче төркем җитәкчесе рәислегендә уздырыла. Эшче төркем җитәкчесе Эшче төркем эшчәнлеген оештыра, Эшче төркем утырышларын чакыра, Эшче төркем утырышының көн тәртибен раслый, Эшче төркем утырышларын алып бара. Эшче төркем җитәкчесе булмаганда, аның вазыйфаларын аның кушуы буенча Эшче төркем җитәкчесе урынбасарларының берсе башкара.

4.3. Эшче төркем әгъзаларына чираттагы утырышны уздыру датасы һәм вакыты, Эшче төркем утырышының көн тәртибе турында хәбәр ителә һәм, утырыш көненә кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, кирәкле материаллар белән тәэмин ителә. Эшче төркем утырышы анда Эшче төркем составының яртысыннан күбрәге катнашу шарты белән тулы хокуклы булып тора.

4.4. Эшче төркем әгъзалары Эшче төркем утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча докладлар, мәгълүмати-аналитик, белешмә һәм башка материаллар әзерләүне оештыра, карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгышлар ясый һәм тәкъдимнәр кертә, кирәк булган очракта, аларны тавыш бирүгә чыгара, кабул ителә торган карарлар проекты буенча тавыш бирүдә катнаша.

4.5. Эшче төркем карарлары утырыш уздырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә. Карар комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Эшче төркем карарлары киңәш бирү характерын йөртә.

4.6. Эшче төркем беркетмәләренең күчермәләре – Эшче төркем әгъзаларына, шулай ук Эшче төркем карары буенча Эшче төркем җитәкчесе кул куйган вакыттан алып өч көн эчендә башка кызыксынучы затларга җибәрелә.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 29 июль, 631 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 27 май, 367 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, эшче төркем җитәкчесе |
| Таҗетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Фәхриев Илназ Инсаф улы | Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшид улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары, Татарстан Республикасының хокук бозуларны профилактикалау буенча хөкүмәт комиссиясе әгъзасы |
| Баксиков Рәсим Рәшит улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Долгов Марат Шамил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы |
| Заика Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы Прокурорының беренче урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кадыйров Рөстәм Рәиф улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы |
| Сабурская Алина Викторовна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Сабурская Сария Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Сәлахов Фәрид Шәүкәт улы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сатдинов Илнур Әмирхәйдәр улы | «Социаль тернәкләндерү һәм адаптацияләү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Столяров Сергей Николаевич | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе башкарма секретаре урынбасары – юридик идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Шакиров Илдар Сәетҗан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Шәфигуллина Олеся Рәдиф кызы | Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең үтәтү һәм хөкем урыныннан азат ителгән соң пробацияләр бүлеге башлыгы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 29 июль, 631 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 27 май, 367 нче
карары редакциясендә)

«Россия Федерациясендә пробация турында»
Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча
муниципаль ведомствоара комиссия турында
бертип нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы ____________________________________________ муниципаль районының (шәһәр округының) «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссиясе (алга таба – Муниципаль комиссия) – пробация кулланыла торган затларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы ____________________________________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм әлеге муниципаль берәмлектә эшчәнлек гамәлгә ашыручы башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче Татарстан Республикасының ___________________________________ муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы каршындагы даими эшләүче координация органы.

1.2. Муниципаль комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә пробация турында» 2023 елның 6 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, ____________________________ муниципаль районының (шәһәр округының) муниципаль хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2019 елның 29 июлендәге 631 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Пробация кулланыла торган затларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы ____________________________________ муниципаль районындагы

(шәһәр округындагы) җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар белән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

1.4. Муниципаль комиссия эшчәнлеге яңадан социальләштерүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә ярдәм күрсәтү күздә тотыла торган затларның ихтыярый теләк белдерүе һәм иреге принципларына нигезләнә.

## II. Муниципаль комиссиянең төп бурычлары

Муниципаль комиссиянең төп бурычлары:

2.1. Татарстан Республикасы _________________________________________ муниципаль районында (шәһәр округында) хөкем ителгән затларга, җинаять-хокук характерындагы башка чаралар билгеләнгән затларга, мәҗбүри эшләр яки иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән, тормышта авыр хәлдә калган затларга карата кулланыла торган чаралар комплексын, шул исәптән түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру:

һөнәри юнәлеш бирү һәм хезмәт адаптациясе;

торак һәм көнкүреш төзелеше;

медицина ярдәме;

белем алу;

социаль хезмәт күрсәтү хокукын гамәлгә ашыру;

психологик ярдәм;

юридик ярдәм;

югалган социаль элемтәләрне һәм функцияләрне торгызуда ярдәм күрсәтү;

пробация кулланыла торган затларны яңадан социальләштерүнең, социаль адаптацияләүнең һәм социаль тернәкләндерүнең башка рәвешләре.

2.2. Пробация кулланыла торган затларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча, шул исәптән вакытлыча тору урынын бирү, пробация үзәген оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы ___________________________________________ муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән эшчәнлеген һәм үзара хезмәттәшлеген координацияләүне тәэмин итү.

2.3. пробация кулланыла торган затларның бердәм реестрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау.

2.5. Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) ________________________ территориясендә пробация кулланыла торган затларны яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү буенча үткәрелә торган эшләр турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү.

## III. Муниципаль комиссия вәкаләтләре

Муниципаль комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

3.1. Яңадан социальләштерүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә булышлык күрсәтү турында гариза биргән затларның социаль хәле индивидуаль тәртиптә карап тикшерелә һәм анализлана.

3.2. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерүнең индивидуаль программа нигезләмәләрен карап тикшерә һәм аларның кулланышына анализ ясый.

3.3. Татарстан Республикасының ___________________ муниципаль районында (шәһәр округында) кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.4. Муниципаль комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

3.4.1. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районының (шәһәр округының) җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан үтәлергә тәкъдим ителгән карарлар кабул итәргә;

3.4.2. Җинаять яки административ җаваплылыкка тарта торган законнарны бозу билгеләре булу ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен тиешле документларны һәм материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә.

3.5. Муниципаль комиссия үз компетенциясе чикләрендә пробация өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен түбәндәге пробация субъектлары булып торган органнар, учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итә:

3.5.1. Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (аның территориаль бүлекчәләре) белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

пробация кулланыла торган затларның бердәм реестры операторы буларак хөкем ителгән затларны, җинаять-хокук характерындагы башка чаралар билгеләнгән затларны һәм мәҗбүри эшләр яки иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән, тормышта авыр хәлдә калган затларны исәпкә алу;

үтәтү яки хөкем ителгән урыннан азат ителгән соң пробацияләр кулланыла торган затлар белән социаль һәм тәрбияви эш уздыру;

яңадан социальләштерүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль тернәкләндерүгә индивидуаль мохтаҗлыкны бәяләү;

үтәтү яки хөкем ителгән урыннан азат ителгән соң пробацияләр куллану турында карарлар кабул ителгән затлар өчен индивидуаль программалар әзерләү;

коммерциягә карамаган, шул исәптән дини оешмаларның, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның пробация үзәге эшчәнлеген оештыру;

3.5.2. Түбәндәге мәсьәләләр буенча эчке эшләр органнары белән:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

үтәтү пробациясен һәм хөкем ителгән урыннан азат ителгән соң пробация куллану;

индивидуаль профилактик эш уздыру;

хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу;

хөкем ителүчене Россия Федерациясе гражданы паспорты белән документлаштыру;

3.5.3. Түбәндәге мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары белән:

халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау (аңа хезмәт күрсәтү) өлкәсендә, шул исәптән мәҗбүри эшләр яки иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм тормышта авыр хәлдә калган затларга социаль хезмәтләр күрсәтү һәм эшкә урнашуда булышлык итү өлешендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

мәҗбүри эшләр яки иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм тормышта авыр хәлдә калган затларга карата эшкә урнаштыру һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә статистика мәгълүматын исәпкә алу;

билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләр белән профилактик эш башкару;

социаль хезмәтү күрсәтү учреждениеләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче балигъ булмаганнарны, шулай ук ирегеннән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны социаль адаптацияләү;

пробация кулланыла торган затларны буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар, хезмәт шартлары, эш хакы һәм вакансияләр эзләүчеләргә карата квалификация таләпләре турында мәгълүмат бирү юлы белән яңадан социальләштерүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә булышлык күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу максатларында һөнәри юнәлеш бирү, әлеге категориядәге билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган затларны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, социаль адаптацияләү буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштыручы эш бирүчеләрне стимуллау;

3.5.4. Беренчел медицина-санитария ярдәмен, профилактик һәм диспансер күзәтүен оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән;

3.5.5. Гомуми белем, урта һөнәри белем алу, һөнәри уку мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән;

3.5.6. Россия Федерациясе Социаль фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге белән пенсия тәэминатын алганда индивидуаль шәхси счет ачу һәм индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган

һәм индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр булган документны рәсмиләштерү мәсьәләләре буенча (пенсия алу хокукына ия затлар өчен);

3.5.7. Дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары белән үз компетенцияләре нигезендә.

## IV. Муниципаль комиссияне төзү тәртибе

4.1. Муниципаль комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

Муниципаль комиссия рәисе:

Муниципаль комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, Муниципаль комиссия утырышларын алып бара;

Муниципаль комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында йөкләмәләр бирә;

Муниципаль комиссия тарафыннан кабул ителә торган документларга кул куя;

Муниципаль комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җавап бирә.

Муниципаль комиссия рәисе урынбасары:

комиссия рәисе кушуы буенча Муниципаль комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын башкара;

Муниципаль комиссия карарларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыра.

Муниципаль комиссия секретаре:

Муниципаль комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

Муниципаль комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

Муниципаль комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга Муниципаль комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) ______________________________________ җирле үзидарә органнарына җәзаны үтәтү системасы учреждениеләре администрацияләреннән затны азат итәчәкләре, аның торагы булу, эшкә сәләте һәм булган белгечлекләре турында керә торган мәгълүмат җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан яңадан социальләштерүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә булышлык күрсәтү турында гаризалар кабул итүне гамәлгә ашыра;

яңадан социальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү программасында катнашучының һәрберсенә даими булышлык күрсәтеп тору картасын һәм шәхси делосын рәсмиләштерә, аларга документлар һәм индивидуаль программа чараларының үтәлеше буенча мәгълүмат кертелә;

«Пробация кулланыла торган затларның бердәм реестры» дәүләт мәгълүмат

системасының муниципаль сегментын алып бара;

муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан Муниципаль комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны соратып ала;

ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләренә кул куя.

Муниципаль комиссия рәисенең аның утырышлары нәтиҗәләре буенча бирелгән йөкләмәләрен үтәүне оештыра;

Муниципаль комиссия функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы ____________________ муниципаль районы (шәһәр округы) халкына мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Муниципаль комиссия составы Татарстан Республикасының ____________ муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы боерыгы белән раслана.

4.3. Муниципаль комиссия составына Татарстан Республикасы ______________ муниципаль районының (шәһәр округының) җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау оешмалары, мәгариф оешмалары вәкилләре (килешү буенча) керергә мөмкин.

4.4. Муниципаль комиссия составына элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, яңадан социальләшү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү буенча уңай тәҗрибәсе булган затлар да кертелергә мөмкин.

4.5. Муниципаль комиссия утырышларында _________________________ район (шәһәр) прокуратурасы вәкиле катнашырга хокуклы (килешү буенча).

4.6. Муниципаль комиссия утырышына дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районының (шәһәр округының) Муниципаль комиссия составына керми торган җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.7. Ведомствоара комиссиядә катнашу җәмәгать башлангычларында башкарыла.

## V. Муниципаль комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Муниципаль комиссия эше даими нигездә башкарыла.

5.2. Муниципаль комиссия утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан яңадан социальләштерүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә булышлык күрсәтү турында гаризалар керүгә карап, әмма елга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Кирәк булган очракта, Муниципаль комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук Муниципаль комиссия әгъзасы инициативасы буенча (Муниципаль комиссия рәисе белән килештереп һәм аның секретаре тәкъдиме белән) Муниципаль комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. Муниципаль комиссия утырышларын муниципаль комиссия рәисе, ә ул булмаганда яисә аның кушуы буенча Муниципаль комиссия рәисе урынбасары алып бара.

5.4. Муниципаль комиссия утырышы, анда составының яртысыннан артыгы катнашу шарты белән, тулы хокуклы булып тора.

5.5. Муниципаль комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия һәм утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.6. Муниципаль комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

5.7. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затның теләге белән утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча уздырыла.

5.8. Муниципаль комиссия әгъзалары комиссия утырышында карап тикшерелгән мәсьәләләр турындагы мәгълүматларны әлеге мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратырга хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматларны тараткан өчен Муниципаль комиссия әгъзалары закон нигезендә җавап бирә.

5.9. Муниципаль комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында, Муниципаль комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.